**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

05.08.2019

КАРАР

ПР-162

Актаныш муниципаль районында 2019 елда бөртекле һәм кузаклы культуралар җыю чорында комбайнчылар һәм механизаторлар арасында ярыш уздыру турында

Авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчыларын һәм механизаторларын авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыруга, үсемлекчелек тармагын үстерүгә матди кызыксындыру максатларында Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчылары һәм механизаторлары арасында 2019 ел уңышын җыю чорында ярышлар үткәрергә.

2. Расларга:

2.1. Актаныш муниципаль районында 2019 елда бөртекле һәм кузаклы культуралар җыю чорында комбайнчылар һәм механизаторлар арасында ярыш уздыру турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә .

2.2. Комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

2.3. Актаныш муниципаль районында 2019 елда бөртекле һәм кузаклы культуралар җыю чорында комбайнчылар һәм механизаторлар арасында ярыш уздыру турында нигезләмәне 3 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына 2019 елгы урып-җыю эшләре йомгаклары буенча Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчыларын бүләкләү өчен финанс чаралары бүлеп бирүне алдан карарга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, http://pravo.tatarstan.ru адрес буенча, һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru рәсми басылып чыккан көненнән, үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Башкарма комитеты җитәкчесе И.Ш. Бариев

Кушымта 1
Актаныш муниципаль районы башкарма комитетының
«05» 08 2019ел ПР-162 санлы карарына

Актаныш муниципаль районында 2019 елда бөртекле һәм кузаклы культуралар җыю чорында комбайнчылар һәм механизаторлар арасында ярыш уздыру турында нигезләмә.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчыларын бүләкләү аларның һөнәри осталыгын күтәрү, хезмәт нәтиҗәлелеген арттыру, урып-җыюда катнашучы хезмәткәрләрнең һөнәри эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында башкарыла.

1.2. Бүләкләү акчалата формада башкарыла.

1.3. Финанслау Актаныш муниципаль районы бюджеты хисабына башкарыла.

## 2. Бүләкләү максатлары

1.4. Бүләкләү түбәндәге максаттан үткәрелә:

- Актаныш муниципаль районының авыл хуҗалыгы җитештерүе хезмәткәрләрен авыл хуҗалыгы продукциясен арттыруга стимуллаштыру;;

## 2. Бүләкләү тантанасында катнашучылар

2.1. Актаныш муниципаль районының авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчылары бүләкләнергә тиеш.

## 3. Бүләкләү тәртибе

3.1. Җиңүчеләрне бүләкләү, составы ТР Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган комиссия карары нигезендә башкарыла.

3.2. Җиңүчеләрне бүләкләү 1000әр сумлык 2 төркем комбайн буенча башкарыла:

4.2.1. Мега-360, Акрос-595, 585, Нью-Холланд, Тукано-430;

4.2.2. Акрос-530, КЗС-1218, ДОН-1500;

## 4. Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчыларын сайлап алуны уздыру механизмы

4.1. Комбайнчылар экипажларын бүләкләү һәр төрдә 5000 ц, 10000 ц, 15000 ц бөртеклеләр суктырган комбайннар буенча үткәрелә.

4.2. Һәр җиде көн саен нәтиҗәләр ясала, комбайнчылар акчалата премия белән бүләкләнә.

Өстәмә шартлар:

а) механизатор эшен исәпкә алу хезмәтне исәпкә алу һәм эшләрне башкару кенәгәсендә алып барыла (механизаторның агротехник паспорты), көндәлек эш күләменә хисапчы, җитәкче, баш агроном кул куя.

б) беренчел документлар (киемнәр, ашлык керү реестрлары) һәм агротехник паспорт белешмәләре сводка буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә тапшырыла торган күрсәткечләргә туры килергә тиеш.

в) мәгълүматларны тапшыру вакыты атнага 2 тапкыр: сишәмбе һәм пәнҗешәмбе

Искәрмә: өстәмә шартлар үтәлмәгән очракта, премия түләнми.

6.1. Комиссия беркетмәсе нигезендә Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге тарафыннан башкарма комитеты җитәкчесенең Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчыларын бүләкләүгә акча бүлеп бирү турындагы күрсәтмәсе проекты әзерләнә.

6.2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе проектында түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш::

- Бүләкләнүчеләрнең исем-фамилиясе;
- күрсәткечләр;
- акчалата бүләк суммасы;

Финанс чыганагы, Актаныш муниципаль районы муниципаль программасының конкрет чарасын күрсәтеп, бюджет классификациясе коды.

6.3. Авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчыларын бүләкләүгә, аларның дөрес һәм вакытында күчерелүенә бүлеп бирелгән акчаларның максатчан тотылышын контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башкара.

Кушымта 2

Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты «05»08 2019 ел.
П 12 санлы карарына

Актаныш муниципаль районында 2019 елда бөртекле һәм кузаклы культураларны урып-җыю чорында комбайнчылар һәм механизаторлар арасында ярышлар уздыру буенча Комиссия составы

Комиссия рәисе:
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе - Мирхәйдәров А. А.,
рәис урынбасары:
авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең механикалаштыру буенча консультанты Н.А.Сәлимгәрәев,

Комиссия әгъзалары:

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе ФИБ начальнигы-Мухаметдинов Д. З.,
ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Актаныш муниципаль районы бүлеге башлыгы – Хәкимов И. М.
Актаныш муниципаль район советының бухгалтер исәбе һәм хисап бүлеге начальнигы-Галимәрдәнова А. А .